**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 14 гыйнвар № 10

г. Казань

Дәүләт ихтыяҗлары өчен җир
кишәрлеген алу турында

«Миңнебай – Казан газүткәргечен 220 – 285 км участогында төзекләндерү» проектын тормышка ашыру максатында, Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының Биектау муниципаль районында урнашкан, «АгроТакт» ҖЧҖ милкендә булган 108,2102 гектар мәйданлы 16:16:040603:108 кадастр санлы җир кишәрлеген (алга таба – җир кишәрлеге) газ белән тәэмин итү объектларын урнаштыру өчен сатып алу юлы белән алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

җир кишәрлегенең сатып алу бәясен билгеләүне һәм аның милекчесе белән тиешле килешү төзүне;

җир кишәрлегенең тиздән алыначагы турында милекчегә хәбәр итүне;

бу карарны дәүләт теркәвенә алу үткәрүне һәм теркәү үткәрелү турында, аның датасын күрсәтеп, милекчегә хәбәр итүне;

милекче җир кишәрлеген алу турындагы карар белән килешмәгән очракта, судка тиешле дәгъвалар кертүне;

сатып алынган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алу үткәрүне.

3. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына җир кишәрлегенең сатып алу бәясен билгеләгәннән соң Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җир кишәрлеген Татарстан Республикасы милкенә сатып алу чыгымнарын финанслау күләме һәм чыганаклары буенча тәкъдимнәр кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында» 2013 ел, 9 октябрь, 737 нче карары үз көчен югалтуын танырга.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\10.docx